ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАЙРЯКИ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Байряки-Тамак, ул.Новая, д.37, , 423964

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘ-ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Бәйрәкә-Тамак авылы, Яңа урамы, 37 йорт,
423964

Тел.:(85593) 5-13-25, факс:5-13-24, e-mail: Btam.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 21 2019 елның 17 июне

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы "  Бәйрәкәтамак     авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге милкендә булган күчемсез
милек объектлары турында мәгълүмат бастырып чыгару
Тәртибен раслау хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, муниципаль милектә булган объектлар турында мәгълүматны бастырып чыгаруны тәэмин итү һәм актуальләштерү өлешендә Россия Федерациясе Президентының 2018 елның 5 апрелендәге Россия Федерациясе Дәүләт Советы (№ Пр-817ГС от 15 май 2018 ел) утырышы нәтиҗәләре буенча карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының “Бәйрәкәтамак авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге милкендәге күчемсез мөлкәт объектлары турында мәгълүматны бастырып чыгару Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Башлыгы З.М.Әгълиева

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкәтамак авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2019 елның
17 июненнән булган №21
Карарына Кушымта

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Бәйрәкәтамак авыл җирлеге » муниципаль берәмлеге милкендә булган күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат бастырып чыгару Тәртибе**

1. Әлеге тәртип аның белән кызыксынучы барлык кешеләрнең дә файдалана алуын тәэмин итү максатларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - Интернет челтәре) Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге милкендә булган күчемсез милек объектлары турында мәгълүматны бастырып чыгару процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге территориясендә муниципаль берәмлек милкендә булган күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат бастырып чыгару өчен Интернет челтәрендәге муниципаль берәмлекнең рәсми сайты булып http://jutaza.tatarstan.ru/сайты тора.

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Бәйрәкәтамак авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге милкендә булган күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат бастыруга вәкаләтле орган булып Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты тора.

4. Россия Федерациясе закончалыгы нигезендә мәгълүмат бирү чикләнгән һәм бастырылырга тиеш булмаган мәгълүматтан тыш,Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль милек реестрына кертелгән күчемсез милек объектлары (биналар, корылмалар, бүлмәләр (помещения) турында мәгълүмат бастырылырга тиеш.

5. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының " Бәйрәкәтамак авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге милкендә булган күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат түбәндәге төрдә басылып чыга:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль милек Реестрына кертелгән биналар, корылмалар һәм бүлмәләр (помещения) турында мәгълүмат буларак;
- әлеге Тәртипкә Кушымтада китерелгән формалар нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль милек Реестрына кертелгән җир участоклары турында мәгълүмат буларак.

6. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге милкендә булган күчемсез милек объектлары турында бастырылып чыгарылган мәгълүматны актуальләштерү, вәкаләтле орган тарафыннан квартал саен гамәлгә ашырыла.

Кушымта 1
Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы "Бәйрәкәтамак авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге милкендә булган
күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат
бастырып чыгару Тәртибенә

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының " Бәйрәкәтамак авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең муниципаль милек Реестрына кертелгән бинàлары, корылмалары һәм бүлмәләре (помещения) турында мәгълүмат

| № п/п | Объектның исеме | Объектның адресы | Объектның гомуми мәйданы кв.м. | Максатчан билгеләнеше | Чикләү | Файдалануны чикләү |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Бәйрәкәтамак авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең муниципаль милек Реестрына кертелгән җир участоклары турында мәгълүмат

| **№ т/б** | **Участокның кадастр саны** | **Участокның урнашкан урыны** | **Участокның гомуми мәйданы, кв.м.** | **Максатчан билгеләнеш** | **Чикләүләр (аренда килешүләре һәм башка килешүләр)** | | **Файдалануны чикләү** | **Милекче/ вәкаләтле орган** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | **Килешү №** | **дата** | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |